ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 4 өлешендә «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:
а) 1 өлештә «Дәүләт Советы» сүзләреннән соң «, әлеге статьяның $7^1$ өлешендә каралган очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә, «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:
«$7^1$. Дәүләт Советы тарафыннан вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасы урынына Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турында карар кабул итү срогы Дәүләт Советы сессияләре арасындагы чорда тәмамланса, Дәүләт Советы Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турындагы карарны әлеге срок тәмамланганнан соң якындагы утырышта кабул итәргә хокуклы.»;
в) 8 өлештә «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 25 июнь
№ 49-ТРЗ